УДК 801.83

# «ХАЛКЫМ ҖЫЛЫСЫН ТОЕП...»
## *(Гаяз Исхакыйның соңгы көндәлек дәфтәрләреннән)*

В сентябре 2018 года, к 140-летию со дня рождения классика татарской литературы Гаяза Исхаки, организатором фонда «Аяз Тахир (Туркестан Идель-Урал)» доктором Туляй Дуран (Турция) были переданы в дар ЦПМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ богатое наследие писателя, в том числе и дневники. Вниманию читателей предлагается одна из его последних работ. Рукопись датирована «Октябрь, 1953 г.» и подписана самим автором как «18-ая тетрадь из «Стамбульского дневника воспоминаний». Заметки сделаны из больницы, куда писателю приходилось многократно обращаться в связи с ухудшением своего здоровья. Представленная публикация впервые вводится в научный оборот.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Турция, дневники, история, биография.

In September 2018, on the occasion of the 140th anniversary of the birth of the classic of Tatar literature Gayaz Iskhaki, the organizer of the Ayaz Takhir (Turkestan Idel-Ural) fund, Dr. Tulyai Duran (Turkey), donated a rich writer’s legacy, including the diaries. One of his latest works is offered to the attention of the readers. The manuscript is dated «October 1953» and signed by the author himself as «the 18th notebook from the Istanbul Diary of Memories». The notes were taken from the hospital where the writer had to go repeatedly due to the deterioration of his health. The presented publication is introduced into scientific circulation for the first time.

**Keywords:** G. Iskhaki, Turkey, diaries, history, biography.

13 октябрь көнне миннән аз-аз булса да кан алдылар. Шуңарга күрә хасталыгымның нигезе канымда булырга кирәк дигән бер фикергә килдем. Докторлар чынлап та шулай икәнне сөйләделәр. 5 октябрь беренче мәртәбә канымны алып тәхлил итдекләре[1] вакыт минем канымдагы кызыл хөҗрәләр[2] ике миллион тукыз йөз мең күрелгән. Вә халәнки[3], исән-сау кешедә ул дүрт миллион булырга кирәк икән, димәк, минем канымның дүрттән берсе җитешми – андый хәлдә ак хөҗрәләр куәтләнеп китәләр дә, кызылларын ашарга тотыналар вә кан, табигый хәленнән чыгып, үлемгә сәбәп буладыр. 13 октябрьдәге кан тәхлилендә[4] бу кызыл хөҗрәләрнең өч миллион йөз илле меңгә җитүе күренгән. Димәк ки, бер атнада хастаханәдә ике йөз илле мең яңа кызыл хөҗрәләр яратылган. Бу бер казаныш, затән[5], үз-үземне хәсән[6] итүдән бераз җиңеллек сизә идем, аз булса да иштиһам[7] да вә арткан иде. Шул көнне өемә китеп килдем, өйдә тавык чорбасын[8] сөеп ашадым, өстенә ике канат, бер муен да кимердем, һичбер авырлык сизмәдем. Бик тәмле иттереп карбыз да ашадым, каһвә дә эчтем,

[1] Тәхлил итдекләре – анализ ясаулары.
[2] Хөҗрә – күзәнәк, бу очракта тәнчек.
[3] Халәнки – чынлыкта.
[4] Тәхлил – анализ.
[5] Затән – нигездә.
[6] Хәсән – яхшы.
[7] Иштиһам – ашыйсы килү теләгем.
[8] Тавык чорбасы – тавык ашы.



Г. Исхакый көндәлегеннән. 18 нче санлы Истанбул хатирә дәфтәренең беренче бите

сәгать 4 тә чәй дә эчтем. Күңелем ачылып, хастаханәгә төшеп яттым. Сеңерләрем дә, Аллага шөкер, ятышып килә.

*Октябрь, 1953, хастаханә*

Бүген руслар тарафыннан Казан алынуның 401 ел тулган көне – безнең милли кайгы көнемез. Мин хаста булганга, дуслар-иптәшләр бу матәм көненә тупланып, милли шәһидләрнең рухына бер дога кыла алмадылар. Гомумән, мин төртеп-тартып йөретмәгәндә, милли эшләремез бик авыр бара.

Доктор Исмәгыйль Зыя[1] килеп, күңелемне күтәрә торган сүзләр сөйләде. Үземез монда тәшхыйсләр[2] тәмам булгач, Бакыркөйдәге үзе хезмәт итә торган хастаханәсенә чакырды. Хәл алырсың, диде. Китәрменме-юкмы – чакыруы зур эштер. Хәмид Зөбәер[3] бәктән мәктүб алдым. Кәмал Локман[4] бәктән дә гайне рәвештә хат алдым. Бик күп һәмшәһриләр[5] килде-китте, мине ялгыз үз башым калдырмадылар. Халыкның җылы дустлыгы безнең кебек халык юлында хаста булганнарга мәгънән шифалы дару кебек буладыр. Ашау-эчүне генә юлга куя алмыйм.

*15 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Көнем бик авыр кичте. Докторым бүген рентген алачак булганга – кичтән йомшартыр өчен бер дару бирде, иртә берлә карынны юарга кушты, шул әмерен һәмширәгә дә сөйләде. Иртә берлә миңа каһвә бирмәделәр. Мин дә, мигъдәм[6] бераз йомшарганны күреп, һәмширәгә һәм тизрәк инәләремне ясарга һәм дә карын юуны ашыктырырга үтендем. Вакытында боларның берсе дә эшләнмәгәнгә, карын юучы хезмәтчене эзләдем. Беркем дә килмәде. Менә мине рентгенга чакырдылар. Лаваҗ[7] дә ясамаенча, инәләремне дә алмаенча, рентген

[1] Доктор Исмәгыйль – Исмәгыйль Зыя Терегул.
[2] Тәшхыйсләр – анализлар.
[3] Хәмид Зөбәер – Хәмид Зөбәер Кошай (1897–1978).
[4] Кәмал Локман – (1899–1976), югары нефть инженеры.
[5] Һәмшәһри – якын, якташ.
[6] Мигъдәм – ашказаны.
[7] Лаваҗ – эчәкләрне юдырту.

бүлмәсенә мендем. Анда дүрт-биш доктор, берничә читтән килгән танышлары – докторлык берлә һичбер мөнәсәбәте булмаган – коры сөйләп торалар, бертуктамаенча ишек ачылып, берсе арты берсе – әле бер хатын, бер ир кеше – кереп, сүзгә кереште. Кайберләре ишек төбендә тупланып торалар, алар янына әллә кемнәр керә. Һәмширә керә яки доктор килә, бер доктор чыга иде. Рентген бүлмәсе бер хан бүлмәсе хәлен ала иде, ул да булмады, берсе керде, докторлардан берсе берлә күреште, күрешкән доктор да үзе башка докторлар берлә таныштыру вә бу кешедә корчаңгы булуын сөйләде. Ике доктор безне утырган йиребездән калдырып, корчаңгыны карадылар, аңа рецепт биреп чыгардылар, бер хатын биш-алты яшьлек баласын алып керде. Баланы рентгенга алдылар, рәсмияне яздылар, чыгардылар. Тагын бер хатын килде. Халык кереп торды. Биш-алты доктор. Өч-дүрте һаман лыкырдып, шаулашып сөйләшеп тордылар. Берәр сәгать вакыт кичте. Миңа сира[1] килде. Тишендем, рентгенга кердем. Тәмсез ак нәрсә эчәргә бирделәр. Бинаһая куе ясалган. Тегеләргә караганда бик авыр эчелә иде. Мең бәла берлә көчкә генә бер стакан эчтем. Шуны бетәрбетермәс рентген алуы кирәк иде. Доктор иптәшләре берлә мәгънәсез сүзләргә тотынды. Биш-ун дәкыйка[2] вакытны бушка йибәрде. Рентген алырга кирәклеге хәтеренә төште. Ак нәрсә агып беткән икән, тагы стакан эчерттер, диде. Мең бәла берлә эчтем. Агып йитүеннән элек рентген фильмасы чикте. Тагын лыгырдарга тотынды, тагы теге зыкым агып бетте, өченче стакан тагын китерделәр. Тагын эч. «Бу юлы сезнең тотышыңыз бетсен дип көтәм. Моннан элек ике стаканда һәрбер аш бетә иде һәм дә зыкым бу кадәр авыр булмый иде. Сез, сүзгә мавыгып, мине онытасыз, – дидем. Доктор бераз оялды булырга кирәк. Бу юлы берсе арттан берсе бер-ике-өч фильма чәкде[3]. Биш-ун дәкыйкадән соң тагы бер стакан эчереп, фильма алды. Тәмам, диде, китимме, дидем. Китегез, диде. Киттем. Мин һеморроемны карарга башка бер доктор көтеп тора икән, ул мине туктатып, әллә ниләр тыкты. Янындагы докторларга: «Эчтә бер каты нәрсә бар, тирән керергә манигъ була[4]. Икенче мәртәбә карарга кирәк, – диде. – Сәгать уникегә кил», – диде. Котылдым дип торсам, тагы рентгенга чакырдылар, бишенче стакан эчертеп, тагы берничә фильма чәкделәр. Аллага шөкер, котылдым, ләкин мәгъдәмдә биш стакан, ул тулган иде. Карынымны юдырырга теләдем. Чәй вакыты җитте. Чәй эчәр өчен хезмәтчегә чалам[5], килмәделәр, тагы чалам, тагы юк. Тагы чалам, тагы юк. Карасам, безнең зилне[6] бозып киткәннәр, сәгать дүрт ярым булды, биш булды. Кемне дә таба алмадым. Биш ярымнарда бер кызны табып,

[1] Сира – чират.
[2] Дәкыйка – минут.
[3] Фильма чәкде – рентгенга төшерү.
[4] Манигъ була – тыела.
[5] Чалам – дәшәм.
[6] Зилне – звонок.

мең бәлаләр берлә бер бардак[1] чәй китертә алдым. Шулай итеп, авыр көнем үтте, хәерле булсын.

*6 октябрь, 1953, Хасәкә хастаханәсе*

Фильмам хакында мәгълүмат бирмәделәр. Фильмалар мондагы докторларны канәгатьләндермәгән. Тагы бер мәтәбә чигәчәксез, диделәр. Ләкин мин Мөхлис исемендәге рентгенчыга ышанычым бик аз. Вазыйфаи-шинаслыгы да юк. Һеморрой хакында калын багырсакта[2] каты-каты сөял сыман кабырчыклар бар диелгән, алар да кан сызуга сәбәп булу ихтималлары булырга кирәк.

Рәсулзадәдән[3] безнең шивәләрдә сөйләшүгә каршы бер протест кәгазе килде. Шуңарга минем дә имзамны эстәгәннәр. Имзаны аттым. Шуны «Милли байрак»ка да җибәрергә булам. Ибраһимга озын хат яздым. Кәефем уртача, бүген Җәгъфәр углы берлә Октай[4], башка беркем килмәде. Сәгадәткә хат яздым.

*Октябрь, 1953, Хасәкә хастаханәсе*

Бүген базар мөнәсәбәте берлә зиярәтчеләрем шактый күп булды. Гайшә ханым тавык чорбасы китерергә булды. Гали Чистайлы Хәлимә ханымнан мәктүб берлә үзе пешергәнне китерде. Окай Әйналыларга мәктүб язарга кушкан идем, генерал әллә ниләр караштырып, Мюнихта калдырган кешеләремезе дә яманлап, бер нәрсә язып китерде. Моның рухында һәркемгә бер дошманлык бар. Мәктүбен җибәрмәдем. Үзем Ибраһимга бер озын хат яздым. Хәмид берлә Локманга икесенә бер хат күндереп, хәлем авырайса, васыятем буенча аларны тәгъйин итдекем[5] өчен, көнлек хатирә дәфтәрләремне тәслим[6] өчен, берсенең килүен риҗада[7] булындым. Сәгадәткә хат язып, ректорлыкыннан мондагы ректорга бер кәгазь яздырып, мине профессор кызның атасы булу сыйфаты илә хастаханә өчен түләтмәүләрен тәэмин итәргә тырыш, дидем. Көнем авыр, күңелсез кичте. Закир Кадыйриларга[8] хат яздым.

*18 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Бүген шәһәргә чыгарга изен[9] алдым. Ун сәгатьтә чыгып, Сәдад бәк хастаханәсеннән рецепт язылган ике төрле алтышар ампуллары алдым. Сәдад бәк булмаганга, тулы бәясен, ун лира түләдем. Алардан Садри бәкләргә телефон әйтеп, сезгә ашка киләм, дидем. Алар да чакырдылар, 12 ләрдә аларга бардым. Гүзәл бер татар чорбасын,

---

[1] Бардак – чынаяк.

[2] Багырсакта – эчәктә.

[3] Мәхмәд Әмин Рәсулзадә – (1884-1955) – күренекле азәрбайҗан сәяси эшлеклесе, әдәбият галиме, язучы.

[4] Октай бәй – медицина докторы.

[5] Тәгъйин итдекем – билгеләвем.

[6] Тәслим – тапшыру.

[7] Риҗада – үтенү, сорау.

[8] Закир Кадыйри (1878–1954) – гарәп теле белгече, журналист, публицист, тәрҗемәче.

[9] Изен – рөхсәт.

бер табак солы, алты кечкенә көфтә[1], беразда булгур пылавы, аннан соң шактый күп йөзем ашадым, хастаханәгә кергәннән бирле бу кадәр иштиһа[2] илә бу чикле аш ашаганым юк. Аштан соң каһвә дә эчтем. Бу ашлар нә ашказанымда, нә дә эчемдә бер авыр ясамады. Сәгать өчләрдә алардан чыгып, иртәгә ясалачак рентген өчен фильмалар даруларын алдым, тугыз лира 60 грош түләдем. Аннан соң өемә кайтып чәй эчтем. Кирәкле әйберләремне алып, сәгать җидедә хастаханәгә дүндем. Өемдә «Париж блок»тан бер хат таптым. Көнем күңелле кичте. Иртәгә икенче мәртәбә рентген фильмасын алачаклар.

*19 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Иртә берлә иртәнге каһвә бирмәделәр. Рентгенга кадәр ач калырга тиеш. Эчне юар өчен лаваҗ ясадылар, ләкин эчтән күп нәрсә чыкмады. Сәгать 12 яртыда гына рентгенга чакырдылар, рентген докторы: «Торыңыз, әүвәле эчеңез бушаганмы, шуны карыйм, – дидем. Рентген машинасының аркасына бастырды, эчне карады. 16 октябрьдә эчкән ак матдә эчәктә туп-тулы... Рентген алдыруым өченче мәртәбәгә кичектерелде. Ягъни ике атнада адәм гакыллы бер фильм ала алмадылар. Моңарга кәефем төште. Гайшә ханым бик тәмле тавык чорбасы, тавык канатлары, тавык муены китерде. Аны кайнарлата сөя-сөя ашадым. Көн күңелсез кичте. Беркем дә хәлемне белешергә дә килмәде. Иртәгә эчемне юачагымыз, диделәр. Бу эшне дә җаһил хезмәтчеләргә эшләткәнгә, әллә нинди яңа-яңа хасталыклар ашламасыннар диеп куркам да, Тәңре ярдәмчем булсын.

*20 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Эчемне бик тирәннән юдырдым. Шактый бушанып калдым. Үземдә җиңеллек тойдым. Нияз Максудига,[3] Хәмид Рәшидкә[4] мәктүбләр язып, «Америка тавышы»ында төрек-татар ләһҗәләрендә сөйләүләр ник туктатылды дип җавап сорадым. Бүген зиярәтчеләр шактый күп килде. Фатих әфәнденең углы Гомәр килде. Шәһәр гайбәтләре юк икән. Сөйли алмады. Бер төрле даруымны китерергә булып китте, аннан соң Мәрьям ханым килеп чыкты. Аның өстенә Мәхмүд килеп чыкты. Аңарга «Америка тавышы»ның безнең телләрдә сөйләвен туктатуына хәзерләнгән протест язуы нөсхәләрен машинада арттырырга бирдем. Фатих бәкләргә барып чыгып, җомга иртәсе юынырга мөмкинме-түгелмене белешеп, хәбәр итәргә куштым. Акчасызлыктан зарланды да үзенә 10 лира сәдака бирдем. Аннан соң Нурулла бәк килеп чыкты. Ул да кәефсез икән. Аның берлә озын гына сөйләшеп утырдык, бергә чәй эчтек, шулай итеп көн үтеп китте. Әнкарага Хәлим агага хат яздым.

*21 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

---

[1] Көфтә – котлет.

[2] Иштиһа – ашау теләге.

[3] Нияз Максуди – Троицк каласында мәдрәсә мөдире.

[4] Хәмид Рәшит – (1912–1964) – Г. Исхакый белән бәйләнештә тора.

Бүген һичбер үзгәреш булмады. Өйләдән соң Хәбибнең абзасы почта-телеграф мөһәндисе Рәхми бәк килеп чыкды. Аның берлә озын гына сөйләшеп утырдык. Ахшам йиймәкенә[1] доктор Октай үзләренә килергә докторлардан рөхсәт алган иде. Сәгать 6 ларда аларга киттем. Барышлый Япониядәге Хөсәен Биглитсига һәм дә Әнкарадагы Хәлимә ханымга берәр хат салдым. Октайларда ашка диеп Төркестанлы Забит Нигъмәтне хатыны берлә чакырганнар иде. Озын сөйләшеп утырдык. Ашлары сәгать сигездә генә бирелде, бик һәйбәт бер табак чорба ашадым, аннан соң бер порцион итле-кишерле бер табак пылау, берничә кашык йогырт, ике уртача кисәк кавын йийдем[2]. Каһвә, ике стакан чәй эчтем. Һичбер авырлык хис итмәдем. Сәгать 10 да гына хастаханәгә кайтып яттым. Яхшы йокладым.

*22 октябрь, 1953. Хастаханә*

Һич яңа нәрсә юк. Фильмамны алмаслар микән дип көткән идем, булмады. «Париж блок»тан килгән блокның низамнамәсен укып тасдикъ иттек[3]. Генералдан кыска гына бер хат яздырдым. Уны күндерттем. Мостафадан бер хат килеп чыкты. Солтан бу вакытка кадәр һичбер мәкалә язмаган, димәк аңарга ышануымыз да бушка чыгачак. Мостафа хатта Мюних радиосына Габдулла Атласи[4] киләчәк имеш, дип яза, ул да үзенә бертөрле хафаланырга тотынырмы, белмим. Мөхәммәд килеп чыкты. Төрек ләһҗәләрендә сөйләүне туктату хакында протест кәгазен шөбһәләндереп китерергә кушкан идем – шуны китерә алмаган... Иртәгә, насыйп булса, өемә кайтып китәм. Бүген ашлар бик начар булды, тәмамән ач калдым.

*23 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Бүген шимбә көн. Тышка чыгарга рөхсәт бирделәр. Өйдә тавык чорбасы пешерергә кушкан идем, шуны ашадым. Һәйбәт булды. Аннары Садриларга барып чәй эчтем. Сәгать 7ләргә Касыйм бәкләргә барып чыктым. Алар да ахшам йиймәке йийдем һәм ваннага кердем. Шактый керләнгән икәнмен. Бик һәйбәт юындым. Мин хамамнан чыкканда, доктор Исмәгыйль Зыя берлә Һидаять бәк[5] килгәннәр иде. Алар берлә чәй эчтек. Һидаять яңа хәбәр китергән. «Идел-Урал ярдәмләшү җәмгыяте» хакында полиция килеп мәгълүмат эстәмеш. Кирәк Исмәгыйль, кирәк Һидаять, кирәк Мәрьям ханым булсын, тәхкыйкать берлә җәмгыятемез ябылачак булса, Ләбибтән аерылуны рәсмиләштерергә кирәк, диделәр. Исмәгыйль бәк базар көне Садри бәкне күреп, аннан бераз юлларын өйрәнеп, дүшәмбе көн тупланып катгый карарга багларга булдылар. Мин Касыйм бәкләрдә кунып калдым. Касыйм бәк бераз хаста. Иртә берлә өемә кайтып киттем. Анда

[1] Йиймәкенә – ашавына.
[2] Йийдем – ашадым.
[3] Тасдикъ иттек – раcладык.
[4] Габдулла Атлас – Япониядән килгән Габдулла Гаффар-Атлас.
[5] Һидаять Яшен – укытучы һәм журналист.

аш хәзерләүче килгән иде. Шул арада Хәсән килеп чыкты, бергәләп аш ашадык, сәгать икенче яртыда хастаханәгә килеп яттым. Идел белән Галим килделәр. Идел алма бәлеше китергән. Алар киткәч, алма бәлеше берлә чәй эчеп ятканда, Билал Газиз бәк килеп чыкты. Ул хастаханәдән ашыгып чыкмаска димләде. Үзем бик туйдым. Гомумән, ашлары үзе тәмсез, үзе суык булганга, бик быкдырды[1]. Закир Кадыйрилардан[2] 2 сеннән дә хат алдым. Мюнихтан соң бераз бугаз авырта. Ангин-фәлән була күрмәсен.

*25 октябрь, 1953*

Сәгадәттән бу атна һичбер мәктүб ала алмадым. Октайга да телефон карадым. Анда да бер хәбәр юк. Мин юкта Мирза Бала[3] белән Ибраһим килеп киткәннәр.

*25 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

26–27 октябрь көннәре эсселегем 37 дән бераз артты, нәшьәм[4] дә кимеде. Иштиһам да азайды. Бераз суык алдырдыммы? Әллә өч-дүрт көннән бирле дәвам итә торган кабзым[5] моңарга сәбәпче булдымы.

Бу көннәрдә зиярәтче дә аз булды. Гайшә ханым гына тавык чорбасы пешереп китерде, ләкин иштиһам аз булганга, аны да бик ашый алмадым. Шәһәргә дә чыга алмадым. Мәхмүд кенә килде, утардан гыйлаҗларны[6] алдырдым. Сәгадәттән мәктүб килеп җитте. Хастаханәдә яту акчасын бирүдән котыла алмаячакмыз дип җавап язды. 12 көн элек фильма алганда эчкән зыкым һаман чыгып бетмәгәнгә, шул да эсселек артуга сәбәп булгандыр. Хастаханәнең тәрбиясеннән, дарулау ысулыннан бик беттем. Ике көн берсе аркылы берсе мөсһил[7] алып мәгъдәмне бераз тәмизләдем[8] дип уйлыйм, бакалым, ни булачак. Бүген шәһәргә чыгарга уйлыйм. Генерал килми, ди. Ул монда яңа бер уен уйнарга маташа ахрысы.

*28 октябрь, 1953 ел. Хасәкә хастаханәсе*

28 октябрь Садри бәкләргә ахшам йиймәкенә җай килмәгәнгә, өйләдән соң хастаханәдән чыгып, өемә килеп чәй эчтем, иртәгә Төркиядә җөмһүрият игъланының утызынчы елы тулганга, шул бәйрәмне каршылар өчен, бик зур хәзерлек алып бара. Урам буйлап меңле-меңле электрик лампалары тагыла иде. Үзем өемдә булганда Конихолумнан мәктүб, Хәмид Рәшидтән бер мәктүб килеп чыкты. Хәмид Рәшит мәктүбендә Нью-Йоркта әзерләнеп, Идел-Урал истикъляль тәшкиләтен коруларын, ләкин аңарга иске мөһаҗирләрнең бик

[1] Быкдырды – туйдырды.
[2] З.Кадыйри (1878–1954) – гарәп теле белгече, публицист, тәрҗемәче.
[3] Мирза Бала (1898–1959) – язучы, «Мөсават» партиясе рәисе.
[4] Нәшьәм – кәефем.
[5] Кабзым – эч кату.
[6] Гыйлаҗларны – даруларны.
[7] Мөсһил – эч җибәрүче.
[8] Тәмизләдем – чистарттым.

аз катнашуларын язадыр. «Америка тавышы»нда төрки ләһҗәләрендә сөйләүне туктатуның сәбәпләре хакында җәмигъ мәгълүмат бирмидер вә халәнки[1] без шуның асыл сәбәпләрен беләсемез килә иде, ялгыз Мюнихтагы борадәр өчен Нью-Йорктан берничә кешенең имзалы булуын белдерде. Америка комитеты Нияз Максудка да Мюнихка барырга тәклиф иткән[2]. Ул үзе генә барырга риза булмаган, Габдулла Атлас, тагы берсе бер Мюнихка барамыз диеп мөрәҗәгать иткәннәр, ләкин әле мәсьәләләре хәл ителмәгән. Хәмид Рәшит, [...] Мюнихка килергә теләмәгәннәр. Конихолумның мәктүбен алып Садриларга киттем. Анда Рәшид бәк, Мөхәммәд керәсе барлар иде. Рәшид бәктән Конихолумның мәктүбен тәрҗемә иттердем. Конихолум иске заляләтендә – мәҗмуганы гарәп хәрефләре берлә чыгармакны – Идел-Уралларыны берлә берләштерегез дип тәкъдимдә булына – мәҗмуга акча ярдәме соравымызга әле мәҗмугалар хакында финанс карары бирелми, ди, бирелү берлә сез читтә калмассыз, дип өмет бирә. Үзенең Истанбулга килүе кичегүе күзгә ташлана...

Безнең милли хәрәкәтемездә сәлби[3] роль уйнаган гонсырларын алга сөрүдән ваз кичә алмыйлар. Конихолумга тәфсилле изахлы бер мәктүб язарга карар бирдем, ләкин шуны я русчага, я инглизчәгә тәрҗемә иттерүдә зәхмәт чиктем. Генерал русчаны яхшы каврагаң[4], ләкин язуларында тәхкыйк,[5] бер эшне боза торган, берәр зөмрәне хөрмәтсезләндерә торган үзеннән бер нәрсәләр гыйлавә итмәенчә[6] калмый, шуңарга күрә аңарга ышанычым аз. Рәшид бәк инглизчә гүзәл яза, әмма эше бик күп булганга, бик озын сөрә. Мәсьәләне актуаль итәсе гаиб булып китәдер, шул мөшкелэтем бик зур. Акча берлә эшләтү бер яктан сер чыгу ягыннан хәтәрле, бер яктан акчамыз юк, хасталыгым да манигъ[7]. Шуңарга авырлык хис иттем. Садри бәктә бик һәйбәт аш ашадык. Камилә ханым, фәүкылгадә тәмле пилмән пешергән иде. Табак ярым ашадым, аннан соң үзенә бер ысулда кәбестә пешергән иде. Аны да ашадым. Үзем дә йидем, ахырдан ике стакан чәй дә эчтем, һичбер авырлык хис итмәдем, сәгать 11 дә генә өемә киттем. Таксим мәйданына килдем. Таксим мәйданы нурга күмелгән.

*29 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре* ***Гарипова Ләйлә Шамил кызы*** *әзерләде*

[1] Халәнки – чынлыкта.
[2] Тәклиф иткән – кушкан.
[3] Сәлби – кире.
[4] Каврагаң – аңлый.
[5] Тәхкыйк – һичшиксез.
[6] Гыйлавә итмәенчә – өстәмичә.
[7] Манигъ – киртә.